Вәһһәбиләр мөселманнарны ышандыру өчен “Әһли Сөннәт үәл-Җәмәгать” исемен үзләре өчен кулланалар. Алар үзләренә нинди булса исем кушсалар да – һичвакыт ышанмагыз! Зинһар, сак булыгыз!!!

[1] Тәвәссүл: берәр мөселман: “Йә, Аллаһым, Пәйгамбәр хөрмәте өчен мине гафу ит! ” яки: "Йә, Рабби, фәлән изге әүлия хөрмәтенә минем гөнаһларымны кичер!” һәм шуңа охшаш сүзләргә “тәвәссүл” дип әйтелә.



# БИК МӨҺИМ БЕР ҮГЕТ-НӘСЫЙХӘТ

“Вәһһәби” фиркасы кемнәр олар?!

Кадерле, Мөселманнар!

Әссәләмү аләйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәтүһ!

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Коръәндә әйтте:

(وَمَن يُشَاقِقِ الرَّسُولَ مِن بَعْدِ مَا تَبَيَّنَ لَهُ الْهُدَى وَيَتَّبِعْ غَيْرَ سَبِيلِ الْمُؤْمِنِينَ نُوَلِّهِ مَا تَوَلَّى وَنُصْلِهِ جَهَنَّمَ وَسَاءتْ مَصِيرًا {115})

Ән-Нисә Сүрәсе, 115-че Аять

<u>Мәгънәсе</u>: *“Һәр кем үзе өчен Пәйгамбәребез өйрәткән хак юлны белгәннән соң бу юлга кршы булып, мөселманнарның дөрес (Әһле Сөннәт үәл-Җәмәгать) юлыннан башка юл сайлаган булса (ягъни адаштыручылар юлына баскан булса), Аллаһ оңа башлаган эшен башкарырга бирер һәм Җәһәннәмгә кертер. Җәһәннәмгә төшү бик авыр җаза булыр”.*

Пәйгамбәребез Мухәммәд, *ʿаляйһиссәләм*, Хәдис Шәрифендә әйтте:

”أوصيكم بأصحابي ثم الذين يلونهم ثم الذين يلونهم ثم يفشو الكذب و عليكم بالجماعة و إياكم و الفرقة فإك الشيطان مع الواحد و هو من الإثنين أبعد فمن أراد بحبوحة الجنة فليلزم الجماعة“

Бу Хәдисне Ибн Хиббан вә Әт-Тирмизий имамнары риваять иттеләр.

<u>Мәгънәсе</u>: *“Сезгә васыятьем – миннән соң Сахәбәләрем һәм алардан соң яшәячәк кешеләр вә алардан соң яшәячәк кешеләрнең юлыннан тайпылмагыз – адашмагыз. (димәк, бәхетле, сәгадәть вакытлар – “Аср-у Сәгада” дә килеп киткән Сахәбәләр, тәбигыйннәр һәм алардан соң яшәгән тәбигый-тәбигыйн күрсәткән юлдан бару әмере күрсәтелә).*

*Аннан соң ялганчылык (алдау) таралыр, (әлеге*

*заманда бу эшне күрәбез), Җәмәгаттән айырылып бүленмәгез! Дөреслектә шәйтан бер кеше белән бергә булыр (җиңел җиңәр), ике кешедән бик ерак булыр. Җәннәткә керергә теләгән кемсә Җәмәгаттән айырылмасын!”*

Аллаһ Тәгалә безгә бу өммәтнең борынгы заманда яшәгәннәрне (Сахәбәләр, тәбигыйн, вә алардан соң яшәгән галимнәрне) үрнәк итеп алырга Әмер итте. Пәйгамбәр әфәндебез, *ʹаляйһиссәләм*, бу Өммәтнең бөекләре булган Сахәбәләр, тәбигыйн вә алардан соң яшәгәннәрнең юлыннан тайпылмаска Әмер итте. Кем Сәләф-Салихларның (Пәйгамбәребезнең гасырында һәм аннан соң ике гасыр эчендә яшәгән Сахәбәләр, тәбигыйн вә аларның юлында булган изге кешеләр) юлын сайлап алган булса – авыр хәлләрдән котылыр, өстен чыгар һәм Ахирәттә бәхетле булыр.

Чөнки Сәләф-Салихлар – иң дөрес булган – Пәйгамбәребезнең хак юлыны ташламыйча, адашмыйча тотканнар, шушы юл белән барганнар, бу эш – болытсыз көн уртасында ялтыраган кояш кебек күренә һәм безгә мәгълүм.

Соңгы вакытта һич гыйлем алмаганнар, белемнең исен дә тоймаганнар, чәй-кофе эчеп, сату-алу белән генә гомерләрен уздырып, буш сүзләр белән вакыт уздырып торган җәһил – нодан кешеләр күбәйде.

Алар сакалларын озынайтып, үзләреннән башкаларны кимсетеп үрегән кешеләр. Үзләре эш күрмиче, этиләрнең кәсеп иткән малларын сууырып торалар.

Һәм алар акча-малның кадерен белмәстән тәкәбберләнеп шул акчаларны вә үз көчләрене яманлык



итте, Пәйгамбәребез – Сөннәтендә (Хәдисләрендә) күрсәтте вә аны тотарга кушты.

Хәлебез – хәл, шул дәрәҗәгә җитте: вәһһәбиләр Аллаһка урын вә тараф (як) кушалар (нисбәт итәләр), һәм "Гарш өстендә утыра", дип сөйлиләр. Ошбу да потпараслекнең үзе! (потларга табынуның үзе)

15. Бик мөһим булган фарзларга, эмерләргә вә хәрамнәргә (шәнаһ – ярамаган эшләргә) карамастан, колак салмыйче, игтибар итмиче үз башларына килә торган шәйтани фикерләр белән мөселманнарны бүләргә, парчаларга, вакларга тырышып эш кылалар.

Кешелек арасында кирәкле булган: фарзларны үтәүдән ваз кичү, гөнәһларга батыра торган эшләр: аракы эчү, риба белән шөгелләнү (процент алу), ришвәт белән эш күрү (взятка) һәм башка шуңа охшаган төрле фәхиш эшләр кылу, гөнәһларга батуларына каршы әйтелгән сүз булса да, алар һичбер үзгәртүне, йалгыш эшләрен төзәтүне күрергә теләмәгән булып торалар, дәвам итәләр. Аларның эшләгән эш факат өстә сыра белән әйтелгән хосусларыда кичкән батыл нәрсәләр белән (Диндә асылда чыннап көчләре булмаган, нәсыйбләре булмаган), дәлилсез вә сәнәдсез тәһликәле (көфергә төшерә торган, керткән) ялган сүзләре (иддигалары) белән мөселманнарны эшләреннән шөгелләндерүдән башка һич бер нәрсә дә түгел (вакытларын алу өчен, мөһим эшләр кылырга вакытлары калмасын, дип). Бу китапта әйтелгән һәм күрсәтелгән батыл, ялгыш, адаштыручы эшләр бетмәде, алар генә түгел, бу фирканың яман эшләре бик күп, әмма аларның чын битләрен күрсәтү өчен җитәрле.

11. Бу Өммәтнең Сәләфләрдән башлап, Халәфләргә кадәр, килгән (яшәгән), бөек галимнәрнең күбесенә вәһһәбиләр: “адашкан” һәм кайсыберләренә дә: “кяфер”, – диләр.

Үрнәк буларак: Имам Мүхәммәд Әл-Газалий, Әл-Җүвейний, Әр-Разий, Тәкыюддин Әс-Сүбкий, Мүхьиддин ибн Әл-Арабий, Абдул-Кадир Әл-Җәйләний һәм бик күп алардан башка галимнәр. Йөзләрчә-меңнәрчә Әһл-и Сөннәт галимнәрнең бөеләренә кемгә: “адашкан”, “саташкан”, “хак юлдан азган”, – диләр, ә кемгә дә: “кяфер”, диләр.

12. Ислам Динендә хак вә дөрес икәне билгеле булган “тәвәссүл” мәсьәләсен вәһһәбиләр: “ширк” – диләр.

13. Тәсбих – тизпе: мөселманнар тарафыннан йөз йыллардан бирле (мең йылдан да элегерәк башланды, хәтта ки Пәйгамбәребез вакытыннан хатыннар кулланган тәсбихләр) зикр гыйбәдәтен үтәр өчен эшләнгән һәм кулланылган. Вәһһәбиләр тәсбих куллануны “ярамый”, – диләр, гөнаһ булган бидгать (яңылык) дип игълан итәләр. Әмма Хаҗ вакытында үзләре тәсбих саталар: “мөшрикләргә сатабыз”, – дияләр.

14. Мөселман галимнәрнең бөтенесе (җәмәгате) сүз берлегендә әйттеләр: Аллаһ һичбер урында түгел, һичбер тарафта түгел, Ул бөтен кимчелекләрдән пак вә өстен. Ул бөтен тарафлардан (яклардан, җиһатлардан) һәм урыннардан өстен (мәкәннәрдән, җирләрдән, күкләрдән).

Бу сүзләрне галимнәр ни өчен әйттеләр? Чөнки бу ышану юлын Аллаһ Тәгалә – Коръәндә тотарга Әмер



вә явызлык өчен кулланалар.

Мөселманнар арасына фетнә-фәсат чәчәләр. Аларга акча, ярдәм биргән кешеләрне алдаталар: хәерле эш эшлибез – диеп. Хәттә үз якыннарына да ялган сүз әйтеп акча-малларын алалар. Асылда аларның кулларыннан һич бер яхшылык чыкмый.

Динебезне тирән белмәгән халыгыбыз арасында өстен күренер өчен үзләрен: “Саляф-Салих” ягъни “изге Сәләфи” исемен куйдылар. Уйлылар: безнең халык бер ни дә белми, – диеп.

Әмма “Сәләфи” – ул Пәйгамбәребез аңлаткан кебек: Пәйгамбәребез гасырында һәм аннан соң тагын 2 гасыр эчендә яшәгән изге мөэмин-мөселманнар (Пәйгамбәребезнең Сахәбәләре, тәбигыйн вә тәбигыйндән соң килгән изгеләр кавымы).

Инде бу эшне белгән кеше бер сүссез аңлар: вәһһәбиләр Сәләфиләрнең аяк эзләренең үбәргә дә хаклары юк! Дәрәҗәләре төшкән әшәке мәхлүклар.

Үзләре Сәләфиләрне танымыйлар, Сәләфиләр сүзләрен алдын артка алыштырып, мәгънәсен бозып китерәләр.

Аларның телләре әле шул сүз әйтүгә дә әйләнә икән: “Борынгы заманнарда, әүвәл яшәгән галимнәр белән хәзерге вакытта яшәүче галимнәр бозган эшләрне без төзәтергә килдек”, – диләр.

Бу эштән башка алар һич оялмастан Пәйгамбәр әфәндебез *‘аляйһиссәләм*-гә дә, Аның Сахәбәләренә дә, алардан соң яшәгән тәбигыйннәргә телләрен озаталар. Шушы изге кешеләрен мәсхәрәләп шундый сүзләр әйтәләр: “Алар бозган эшләрне, башкара алмаган мәсьәләләрне без генә эшли алабыз, төзәтәбез һәм

башкарабыз” – дияләр, гөнаһтан курыкмастан, сүзләрен кире кайтармыйча, хаталарын аңларга теләмиләр.

Шундый пычырак сүзләр белән яла ягу әшәке эшкә ничек әле телләре әйләнә?!...

Аерыча үзләренгенә “Дин тотучылар”, “Дин саклаучылар” һәм “Динне йөретүчеләр” булганнарын сөйләп, кешеләрне алдатып, башларын әйләндерәләр, иддигъа итәләр.

Ошбу фирканың әгзалары кем булганнарын төшенәсез ме?! Әй, мөселманнар...!

Менә бу фиркага кергән кешеләр – “Вәһһәбийләр”.

Хәзер инде вәһһәбиләрнең кем булганнарын аңлату сырасы (вакыты) килде.

Ун сигезенче гасырның азагында Нәжд бүлгәсенең Димйә авылында “Мухәммәд Ибн Абдул-Вәһһәб” исемле шәхес (кеше) дөньяга килде.

Бу кеше свбыйлык вакытын туган илендә – бүлгәсендә кичерде. Аннан соң “Динне өйрәнү өчен” – диеп, Ирак җирләренә китте. Ә анда инглиз миссионер җәсусы (шпион) белән танышты. Ул җәсусның исеме – Мистер Хәмпвер иде. Шушы җәсус Ибн Абдул-Вәһһәб белән бик якын дус булды, оны төрле мәкерлекләргә өйрәтте,

Аның алдында Ибн Абдул-Вәһһәб мәлҗерәп төшә иде, һич акылын кулланмыйча сүзләрен тыңлар иде, агулы фикерләрен йотты, кабул итте.

Ауропа дәвләтләр (Англия һәм башкалар) тарафыннан Госманлы төркиләр Халифат – мөселман Дәүләтен юк итү максат белән эшләнгән фигыйлдә Ибн Абдул-Вәһһәб роль алды, васыйта – корал булды.

Ахырында үз ватаны-дәүләте булган Нәжд бүлгәсенә



булмаган яман бер яңылык).

Тагын да: Коръән Аятләрендә вә Пәйгамбәребезнең Хәдисләрендә сабит булган (исбатланган) Зикерләр һәм Догалардан башка: “бөтен зикер вә догалар – яман бидгать (яңылык)”, – диләр.

8. Вәһһәбиләрнең сүзләренә күрә үлгән мөэмин-мөселман эти-әниләребез рухларына Коръән Сүрәләрен укырга вә укытырга “харам” (гөнаһ) һәм “яман бидгать”, – дип әйтәләр. Безнең үлеләр Догага мохтаҗлар, ничек инде без аларны сәвапсыз калдырабыз, ничек “Әлхәм” – “Әл-Фәтихә” Сүрәсен, “Йәсин” Сүрәсен, һәм башка Коръән Аятләрен мәрхүмнәребезнең җаннарына укып багышламыйча калдырабыз.

9. Вәһһәбиләр әйтүләренә күрә Тәравих Намазын 20 Ракәгат кылу – гөнаһ дип санала.

Бу эшне алар яман диләр, аны Хәзрәт Гөмәр (икенче халиф) уйлап чыгарган бер яңылык дип сөйлиләр. Шуңа күрә Хәзрәти Гөмәрне Динебезгә бозгынчылык керткән хыянәтче диеп, мыскыллайлар.

Шулай ук, Гомәр Хәзрәтне – “Динне бозгучы, хыянәт кылучы, яман яңылыклар кертүче кеше”, – диеп, яла ягып, хәкарәт (мыскыл) итәләр.

10. Җомга көнендә Җомга Намазының укыла торган икенче Азан билгеле, аны укуга вәһһәбиләр: “яман бидгать (яңылык)”, – диләр, Госман Хәзрәт тарафыннан кертелгән диеп, “Исламда дөрес түгел”, “Ислам Шәригатенә каршы килә”, – дип әйтәләр.

Бу мәгнәдә дә Гөмәр Хәзрәтне мыскыллау кебек, шулай ук Госман Хәзрәтне дә: “бидгатьчы”, – дияләр. (Исламга яман яңылык кертүче дип аңлаталар).

китабында һәм Ибн Фирхун “Тәбсыратүл-Хүккям” исемле китабында әйтелә (зикер ителә).

4. Мең ике йөз йылдан бирле безнең Диндә ышану ысулларын, юлларын аңлаткан, галәмдә яшәгән мөселманнарның күпчелеге ышана торган иманнарын өйрәткән ике хак мәзһәб бар, берәсе – Матуридия, икенчесе – Ашгарийә. Беренчесенең баш Имамы - Әбу Мансур Әл-Матуридий, икенчесенең – Әбул-Хәсән Әл-Әшгарий. Икесе дә дөрес юл белән әлеге заманга кадәр баралар.

Вәһһәбиләр бу ике хак мәзһәбенә игтибар итегез, алар: “адашкан” – диләр.

5. Вәһһәбиләр әйтүләре буенча: “Әбү Җәһил һәм Әбү Ләһәб мүшрикләр бөгенге мөселманнар белән чагыштырганда – мүүәххидләр – иманлары дөресерәк, көчлерәк”. Бу сүзләр һич акылга ятмый. Чөнки Әбү Җәһил һәм Әбү Ләһәб – мүшрикләр мөселманнарга каршы иделәр, Пәйгамбәребезне җафаладылар, кимсеттеләр, төрле явызлыклар эшләп, мыскыл иттеләр. Алар Дин дошманнары, ничек инде аларның иманнары булачак?!

6. Вәһһәбиләрнең фикерләре буенча: башта “Нәкышбәндий” тарикатны вә башка бөтен суфый тарикат әһелләрен (элеке заманнарда аны оештырганнардан башлап хәттә барча мәнсүпләренә кадәр (кем шушы тарикаткә кергән, багланган)): “Алар барчасы – кяферләр”, – дияләр.

Бер ничә йыл элек Әр-Риядта бу мәсьәлә буенча бер фәтвә чыгардылар.

7. Мәчетләрдә Намаз укыганнан соң җәмәгать белән укылган зикерләрне “яман бидгать”, – диләр (Диндә



кайтар алдыннан Сауд улы Мухәммәд белән бергә, Госманлы Дәүләтне тар-мар итәр (таратыр, юк итәр) өчен инглизлар белән берлектә эш алып барырга үзләре өчен файдалы күрделәр. Һәм инглизлар белән үз халыкка, сәясәткә, икътисатка, әдәбияткә, гөреф-гадәтләргә, мәдәнияткә каршы эш башлады.

Госманлы аталарыбыз изге әүлияләрне бик сөйгән булган, чөнки әүлияләр – бик яхшы, сабырлы, үрнәк күрсәтүчеләр, Аллаһы Тәгалә аларга бөек дәрәҗәләр бирде, безгә дә әүлияләрне сөю тиешле.

Иманны кеше әүлияләрне белә һәм хөрмәт итә. Шуңа күрә Мухәммәд ибн Абдул-Вәһһәб үз кешеләрне әүлиләргә “кәфер” вә “мөшрик” диюне өйрәтте.

Тагын да дөреслектә татар-төрекләрне һәм башка охшаш милләтләрне “кяфер” – диләр. Чөнки Госман халифаты вәһһәбиләргә бик нык каршылык күрсәттеләр, сугыш хәленә җиттеләр.

Берәр милләтләрне үтерүе мөмкинчелеге булсын өчен ул кавымны “кяфер” я “мөшрик” диеп, үзенең җәмәгатенә игълан итә иде. Һәм аларга эшандыру өчен үз башыннан (һавадан) шәйтани фәтвәләр уйлап чыгарып: “Буларның каны һәм малы – хәләл, ченки алар Пейгамбәр, әүлия вә изге кешеләрнең каберләренә барып зиярәт итәләр, Аллаһтан башкасына гыйбәдәт итәләр” диеп, зур кавым – бөек татар әтиләребез-бабайларыбызга каршы хыянәт пропагандасын йөретә башлады.

Шулай тарихның иң бөек беренче хыянәтене инглиз кяферләре белән бергә эш башкара, гасырлар буенча Мәккә-и Мөкәррамә, Мәдинә-и Мөнәүүәрәһ вә Мәчет "Әл-Акса" ны саклаган Османлы гаскәрләрне арка

тарафтан хыянәтлек белән үтерә башладылар. Мөселман илләребезне, Ислам мәркәзләрне, мөкаддәс җирләребезне үзебезнең хөкемнән чыгарып, кяфер-гяурләр кулларына бирергә ашыктылар вә күп ярдәмнәр бирделәр! Тәслим иттеләр...

Сахих Әл-Бухарий риваять иткән Хәдистән билгеле: Сахәбәләр Пәйгамбәребез Мухәммәд *ʿаляйһиссәләм* Дога укыр иде "Йә, Аллаһым! Шәм һәм Йәмән бүлгәләргә бәрәкәт бир!" өч мәртәбә шундый Дога кылганда, Сахәбәләр сорадылар: "Ә безнең Нәжд бүлеге, йә, Расүләллаһ!? "

Пәйгамбәребез *ʿаляйһиссәләм* шундый җәвап бирде: "Юк! Аннан шәйтан мөгезе чыгачак!". Һәм дә Пәйгамбәребез *ʿаляйһиссәләм*-нең сүзләре чыннап дөрес булып чыкты.

Галимнәр әйткән буенча шул вәһһәбиләр фитнәсе Нәжд бүлегеннән чыккан бер шәйтан мөгезе була ул!..

Имам Ибн Абидин "Хәшия" китабының "Бәб Әл-Бугат" ("Азгыннар бүлеме") ндә: "вәһһәбиләр – үткән тарихта явыз адашкан хариҗиләр агымының бер ботагы", – диеп безгә аңлатты.

Бу адашкан фирканың батыл ышануларыннан һәм фикерләреннән бир ничә үрнәк китерәбез:

Хөрмәтле Мөселман кардәшләр!

Күрәсез: вәһһәбиләр үз бозык ышануларын җир йөзендә яшәгән мөселманнар арасына чәчмәк өчен кулларында булган акчаларны һәм малларны күпләп сарыф итәләр. Максатлары – һәр төрле сәбәп-мөмкинчелек кулланып, агуларын мөселманнар арасына тарату!

1. Вәһһәбиләр берәр илгә хәким булсалар (хөкем-



рәислекне кулларына алсалар) иң башта кылган эшләреннән беренчесе – бөтен зиратларны (каберстаннарны) җир белән бер тигез итеп, җимереп күмәләр. Бүгенге хәлебез шул дәрәҗәгә килде: Мәккә Шәрифә шәһәрендә (Мәккә-и Мөкәррамә) дә "Җәннәт-ул-Мүәллә" һәм Мәдинә шәһәрендә (Мәдинә-и Мөнәүүәрә) дә "Җәннәт-ул-Бакый" зиратларыбызда яткан меңләрчә Сахәбәләрниң каберләре янына барып зиярәт итәргә теләгәннәр әлеге вакытта кемнең кабере кайда булганы билгеле түгел.

2. Башта Пәйгамбәр әфәндебез *ʿаляйһиссәләм*-не (аларның дәрәҗәсенә күрә), аңардан соң килгән (яшәгән) бөтен Пәйгамбәрләр вә Пәйгамбәрләрдән соңра яшәгән барча изге-әүлияләр белән бергә һәммәсенең каберләреннән бәрәкәт теләү максаты белән зиярәт итүне кабул итмиләр һәм аны: "Ширк (көфер)" булганын сөйлиләр. Бер кеше: "Йә, Мухәммәд!" яки берәр әүлияның юзе-сою хөрмәтенә дип: "Мәдәд, әй, Абдул-Кадир Җәйләни!" йә дә: "Мәдәд, әй, Расүлуллаһ!", дисә, ("Ярдәм ит, әй, Аллаһның Расүле!"), оларның сүзләренә күрә: Диндән чыккан кяфер булыр. (Шундый кешенең малы да, каны да, хатыны да вәһһәбиләр хәләл дип күрәләр. Алырга, кулланырга рөхсәт бирәләр).

3. Үлем фәрештәсе (җан алучы фәрештә) булган вә Пәйгамбәр әфәндебезнең Хәдис Шәрифендә әйтелгән "Газраил" исеме икәне билгеле, миллиардларча мөселманнар арасында мәшһүр "Газраил" исеме билгеле, вәһһәбиләр бу исемне кабул итмиләр, инкәр итеп: "Газраил исемле бер нәрсә дә юк" дияләр, хәттә Имам Әт-Табәраний үзенең "Әт-Тиләүәт" исемле